# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЙДАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

**дүртенче чакырылыш егерме җиденче утырыш**

**Айдар авылы** **№ 80** **18.08.2023 ел.**

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлегенең 2016 елның 10 июнендә №31 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлегенең 2016 елның 06 июнендә №31 номерлы карары (29.05.2017 № 61, 03.06.2017 № 62, 20.12.2017 № 85, 20.12.2018 № 119, 06.02.2019 № 120, 11.09.2019 №136/1, 12.03.2021 №14, 15.11.2021 №27, 10.03.2022 №44, 16.01.2023 № 69 карарлар редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (алга таба текст буенча - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 19 бүлектә:

А) 5 пунктны «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләре белән тулыландырырга;

Б) 7 пунктны «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләре белән тулыландырырга;

2) 23.1 бүлекнең 3 пунктындагы 1 пунктчасын «яисә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты Администрациясенең вәкаләтле бүлекчәсе» сүзләре белән тулыландырырга;

3) 27.1 бүлектә:

А) 3 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының норматив хокукый актлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) норматив хокукый актлары» сүзләренә алмаштырырга;

Б) 7 пунктта «дөрес булмаган яисә» сүзләрен төшереп калдырырга, «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

В) 8 пунктта «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгын (Рәисен)» сүзләренә алмаштырырга;

Г) 9 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) белән» сүзләренә алмаштырырга;

Д) 10 пунктта «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгын (Рәисен)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Айдар авыл җирлеге башлыгы Х.Ш.Хәсәншин